СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**30.09.2016** **№ 23**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Урта Курса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - авылларда юлларны төзекләндерү (вак таш) җәю:<br>Югары Курса ав.<br>А. Алиш ур., 8дән 11гә кадәр,<br>А. Алиш ур., 4дән 23кә кадәр Школьная ур.;<br>- Урта Курса ав.<br>Гагарин ур., 1 йорт, Тукай ур., 11 йорт;<br>Сарай-Чокырча ав.<br>М. Җәлил ур., 8дән 16га кадәр; | 33 700<br><br>37 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Түбән Курса<br>Пушкин ур., 1а йорттан алып 27 йортка кадәр | 21 000<br><br>35 100 |
| | | | 126 800 |

әйе юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Урта Курса авылы, Яшьләр ур., 13 йорт, Урта Курса авылы, Сәйдәш ур., 8 йорт.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

СОВЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609003070